| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.10.2024 г. Казань № 808/2024

Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $47^2$ статьясының 4 пункты нигезендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч түләвенә ышанычсыз дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карары нигезендә

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары Л.В.Хәбибуллинага йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.10.2024 № 808/2024 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе

1. Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итүнең әлеге Тәртибе (алга таба – Тәртип, Дәүләт комитеты) Татарстан Республикасы бюджетына (алга таба – бюджетка) Дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану процедурасын билгеләү максатларында эшләнде.

2. Бюджетка Дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган түләүләр түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) физик затның – Бюджетка түләүләр түләүченең вафат булуы яисә аны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан итү;

б) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә гражданинның, шәхси эшкуарның банкротлык процедурасын бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә тәмамлавы, аны түләү бурычын үтәүдән ул күрсәтелгән Федераль закон нигезендә азат ителгән булуы;

в) оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле Бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча әҗәт өлешендә оешма – Бюджетка түләүләр түләүче зат бетерелгән очракта;

г) штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки ярлыкау турындагы актларны куллану яисә Дәүләт комитеты Бюджетка түләүләр буенча бурычны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, түләтү мөмкинлеген югалта торган карар кабул ителгәндә;

д) «Үтәтү эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 229-ФЗ номерлы федераль закон) 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча үтәтү документын түләтүчегә кире кайтарганда үтәтү эшен тәмамлау турында суд приставы-башкаручысы тарафыннан карар чыгару, әгәр күләме бурычлыга карата банкротлык турындагы эш буенча производство кузгату өчен бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаган бурыч барлыкка килгән көннән башлап биш елдан артык вакыт узып китсә.

е) банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип

тану яисә банкротлык турындагы эш буенча производство туктату турындагы гаризаны суд тарафыннан кире кайтару турында акт кабул итү;

ж) теркәүгә ала торган орган тарафыннан юридик зат Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдырылганда һәм, 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча үтәтү документын түләттерүче затка кайтарып, башкару эшчәнлеген туктату турында суд пристав-башкаручысы тарафыннан элегрәк чыгарылган карар булганда, – оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле Бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча бурыч өлешендә.

«Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә теркәүгә ала торган органның юридик затны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлдә түгел дип танылган очракта, әлеге пунктча нигезендә элегрәк түләттерү өчен ышанычсыз дип танылган Бюджет түләүләре буенча бурыч бюджет (бухгалтерия) исәбендә торгызылырга тиеш.

3. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган очраклар белән беррәттән, түләнмәгән административ штрафлар, әгәр административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда, административ җәза билгеләү турындагы карар үтәлешен туктату турында карар чыгарылган булса, түләттерү өчен ышанычсыз дип таныла.

4. Бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарны Дәүләт комитеты Тәртипнең 2 һәм 3 пунктларында билгеләнгән һәм түбәндәге документлар белән расланган нигезләр буенча кабул итә:

а) Бюджетка түләүләр түләү буенча бурычларның исәпкә алына торган суммалары турында Дәүләт комитетының финанс исәбе, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлеге әзерләгән белешмәсе (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта);

б) Бюджетка Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^1$ статьясы нигезендә билгеләнгән түләүләр, пенялар һәм алар буенча штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү буенча бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында Дәүләт комитетының юридик бүлеге тарафыннан әзерләнгән Дәүләт комитеты белешмәсе;

в) Бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану очракларын раслый торган документлар, шул исәптән:

бюджетка түләүләр түләүче физик затның вафат булуын таныклаучы яисә аны вафат булган дип игълан итү фактын раслаучы документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән очракта);

конкурс эшчәнлеген тәмамлау яисә шәхси эшкуар булып торган гражданин – Бюджетка түләүләр түләүче затның мөлкәтен сатуны төгәлләү турында суд акты, шулай ук Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан үзен бөлген (банкрот) дип тану турында суд акты кабул ителүгә бәйле рәвештә физик зат – Бюджетка түләүләр түләүче

затның шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлеген туктатуы турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән очракта);

конкурс производствосын тәмамлау яисә Бюджетка түләүләр түләүче гражданин мөлкәтен сатуны тәмамлану турында суд акты (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән очракта);

Бюджетка түләүләр түләүче оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшчәнлек туктатылуы турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр булган документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән очракта);

амнистия турындагы акт яисә штраф рәвешендәге җәзага хөкем ителгәннәргә карата ярлыкау акты яисә Дәүләт комитеты Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалта торган суд акты, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә дә (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән очракта);

229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча үтәтү документын түләтүчегә кире кайтаруга бәйле рәвештә башкару эшен тәмамлау турында суд приставы-башкаручысы карары (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «д», «е», «ж» пунктчаларында күрсәтелгән очракларда);

бюджетка түләүләр түләүче затны бөлген (банкрот) дип тану турында гаризаны кире кайтару турында яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне туктату турында суд акты (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «е» пунктчасында күрсәтелгән очракта);

теркәү органы карары буенча Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан юридик затны – бюджетка түләүләр түләүчене күрсәтелгән реестрдан төшереп калдыру турында белешмәләр булган документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «ж» пунктчасында күрсәтелгән очракта);

административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату хакындагы карар (әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән очракта);

гражданинның судтан тыш банкротлыгы процедурасы тәмамлану турында Банкротлык турында белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән очракта).

5. Бурычны түләтүгә өметсез дип тану эшен оештыру максатларында документлар активлар керү һәм китү буенча Дәүләт комитеты тарафыннан даими нигездә төзелгән комиссиягә (алга таба – Комиссия) җибәрелә. Комиссиянең саны кимендә дүрт кеше тәшкил итә. Комиссиянең шәхси составы Дәүләт комитеты рәисе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) боерыгы белән раслана.

Комиссия составына Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия секретаре, Комиссия әгъзалары керә.

Комиссия рәисе:

Комиссия эшенә җитәкчелек итә;

Комиссия утырышларын үткәрә;

Комиссия әгъзалары арасыннан комиссиянең җаваплы секретарен билгеләп куя

Комиссия рәисе булмаганда аның функцияләрен Комиссия рәисе урынбасары башкара.

Комиссиянең җаваплы секретаре:

Комиссия эшен алып баруны оештыра;

Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында мәгълүмат белән тәэмин итә;

Комиссия рәисе күрсәтмәсе буенча Комиссия эшенә бәйле башка функцияләрне башкара.

6. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма елына бер тапкырдан да сирәгрәк булмаган күләмдә уздырыла. Әгәр Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, Комиссия карары тулы хокуклы була.

7. Әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану нигезләрен раслый торган документлар пакеты контроль-ревизия бүлеге тарафыннан төзелә һәм әлеге Тәртипнең 2 яисә 3 пунктларында каралган очрак килеп чыгу турында Дәүләт комитетына мәгълүмат кергән көннән алып 30 календарь көн эчендә Комиссиягә карау өчен җибәрелә.

8. Комиссия тапшырылган документлар нигезендә Бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турындагы мәсьәләне Комиссиягә кергән көннән алып 15 эш көне эчендә карый.

9. Бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турындагы мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип танырга – әлеге Тәртипнең 2 яисә 3 пунктында күрсәтелгән нигез һәм әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документлар булганда;

бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип танымаска – әлеге Тәртипнең 2 яисә 3 пунктында күрсәтелгән нигез һәм әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документлар булмаганда. Әлеге карар Бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турындагы мәсьәләне кабат карарга комачауламый.

10. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы Комиссия әгъзалары санынннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда Комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып санала.

11. Комиссия утырышы йомгаклары буенча, әлеге Тәртипнең 9 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очракта, утырыш уздырылган көннән алып биш эш көне эчендә Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар проекты әзерләнә.

12. Комиссия карары Комиссия утырышын уздырган көннән алып биш эш көне эчендә Дәүләт комитеты тарафыннан бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтадагы (алга таба – Акт) форма буенча түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган акт белән рәсмиләштерелә:

а) оешманың тулы исеме (физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

б) салым түләүченең идентификация номеры, төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүче – оешманың исәпкә куелу сәбәбе коды (салым түләүче – физик затның идентификация номеры (булган очракта);

в) бурыч барлыкка килгән Бюджетка түләү турында белешмәләр;

г) Бюджетка түләүләр буенча бурыч исәпкә алына торган Татарстан Республикасы бюджетлары керемнәре классификациясе коды, аның исеме;

д) Бюджетка түләүләр буенча бурыч суммасы;

е) Бюджетка тиешле түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммасы;

ж) Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү датасы;

Акт ике нөсхәдә төзелә һәм утырышта рәислек итүче һәм утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

13. Комиссия тарафыннан рәсмиләштерелгән Акт Комиссия тарафыннан имзаланган көннән алып ун эш көне эчендә Дәүләт комитеты рәисе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан раслана.

14. Әлеге Тәртипнең 9 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән очракта, Комиссия утырышы беркетмәсендә Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану өчен нигезләр булмау турындагы мәгълүмат чагылдырыла. Беркетмә утырышта рәислек итүче һәм Комиссия секретаре тарафыннан имзалана һәм белешмә өчен Дәүләт комитеты рәисенә җибәрелә.

Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләү буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган бурычларның исәпкә алына торган суммалары турында

20___ елның «__» __________ №____

БЕЛЕШМӘ

| т/с | Түләү исеме | Түләү суммасы (сумнарда) | Бурычның барлыкка килү датасы | Документның реквизитлары – бурыч барлыкка килү өчен нигезләр (дата, номер) | Бурычлы затның – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), салым түләүченең идентификация номеры (булган очракта); салым түләүче – юридик затның исеме, идентификация номеры, төп дәүләт теркәү номеры, исәпкә куелу сәбәбе коды (булган очракта) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 6 | 7 |
| | | | | | |

Баш бухгалтер (бухгалтерлык исәбен алып
бару йөкләнә торган башка вазыйфаи зат) ___________ ________________________
(имза) (инициаллар, фамилия)

Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында
АКТ

_____________ 20__ ел. № _____

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының активлар керү һәм китү комиссиясе тарафыннан нигезне тикшерү нәтиҗәләре буенча (активлар керү һәм китү комиссиясе утырышы беркетмәсе"__" ______20__ ел, №__) Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге түләүләргә карата бурычлар түләтүгә өметсез дип танылды:

| т/с | Оешманың тулы исеме (физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) | Салым түләүченең идентификацияләү номеры, төп дәүләт теркәвенә алу номеры, салым түләүченең оешмасын исәпкә алуның сәбәп коды (физик зат - салым түләүченең идентификацияләү номеры) (булган очракта) | Бурыч барлыкка килгән түләү турында белешмәләр | Татарстан Республикасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч исәпкә алына торган Татарстан Республикасы бюджетлары керемнәре классификациясе коды, аның исеме | Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч суммасы | Татарстан Республикасы бюджетына тиешле түләүләр буенча пеняләр һәм штрафлар буенча бурыч суммасы | Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | ҖӘМГЫСЕ | | | | | | |

Активлар керү һәм китү комиссиясе рәисе:

____________________ ___________ _________________________

(вазыйфасы) (имза) (инициаллары, фамилиясе)

Активлар керү һәм китү комиссиясе әгъзалары:

____________________ ___________ _________________________

(вазыйфасы) (имза) (инициаллары, фамилиясе)

____________________ ___________ _________________________

(вазыйфасы) (имза) (инициаллары, фамилиясе)